РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ        с. Тюлячи        КАРАР

«24» февраля 2025г.        № 37

О внесении изменений в постановление Исполнительного комитета Тюлячинского муниципального района от 26.09.2024 года № 117 «Об утверждении нормативов финансирования деятельности образовательных организаций, реализующих программы дошкольного образования в Тюлячинском муниципальном районе на 2025 год»

Рассмотрев письмо ГБУ «Центр экономических и социальных исследований Республики Татарстан при Кабинете Министров Республики Татарстан» от 13.02.2025 года № 01/217, в соответствии с Федеральным законом от 6 октября 2003 года № 131-ФЗ «Об общих принципах организации местного самоуправления в Российской Федерации», Исполнительный комитет Тюлячинского муниципального района

ПОСТАНОВЛЯЕТ:

1. Внести в постановление Исполнительного комитета Тюлячинского муниципального района от 26.09.2024 года № 117 «Об утверждении нормативов финансирования деятельности образовательных организаций, реализующих программы дошкольного образования в Тюлячинском муниципальном районе на 2025 год» (в редакции постановлений от 23.10.2024 № 129) следующие изменения:

в Нормативные затраты на оказание муниципальной услуги по присмотру и уходу за детьми в образовательных организациях, реализующих программы дошкольного образования в Тюлячинском муниципальном районе, утвержденные указанным постановлением:

пункт 5 изложить в следующей редакции:

«5. Нормативы расходов на продукты питания в дошкольных образовательных организациях

| Количество часов работы дошкольной образовательной организации | Нормативы расходов на продукты питания, рублей в день/воспитанник | | | |
|---|---|---|---|---|
| | общеразвивающие группы (в том числе разновозрастные) | | санаторные группы | |
| | от 2 месяцев до 3 лет | от 3 лет до прекращения образовательных отношений | от 2 месяцев до 3 лет | от 3 лет до прекращения образовательных отношений |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 3-4 | 33,88 | 42,65 | | |
| 5-6 | 81,28 | 102,39 | | |
| 7-12 | 135,49 | 170,64 | 175,78 | 234,39 |
| 24 | 169,34 | 210,66 | 219,73 | 289,36» |

2. Опубликовать настоящее постановление в соответствии с действующим законодательством.

3. Настоящее постановление вступает в силу в соответствии с действующим законодательством.

4. Контроль за исполнением настоящего постановления возложить на заместителя Руководителя Исполнительного комитета Тюлячинского муниципального района по социальным вопросам Д.С. Гиниятуллина.

Руководитель И.Х. Хамидуллин

| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br><br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br><br>ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

«24» февраля 2025ел № 37

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 26 сентябрендәге 117 номерлы «2025 елга Теләче муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

ДБУ «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» нең 2025 елның 13 февралендәге 01/217 номерлы хатын карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 26 сентябрендәге 117 номерлы «2025 елга Теләче муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында» карарына (2024 елның 23 октябрендәге 129 номерлы карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

күрсәтелгән карар белән расланган Теләче муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында балаларны карау һәм тәрбияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга:

5 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«5. Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында азык-төлек продуктларына чыгымнар нормативлары

| Мәктәпкәчә мәгариф оешмасының эш сәгатьләре саны | Азык-төлек продуктларына, көнгә/тәрбияләнүчегә чыгымнар нормативлары | | | |
|---|---|---|---|---|
| | гомумүстерү төркемнәре (шул исәптән төрле яшьтәге) | | санатор төркемнәр | |
| | 2 айдан 3 яшькә кадәр | 3 яшьтән алып белем бирү мөнәсәбәтләре туктатылганга кадәр | 2 айдан 3 яшькә кадәр | 3 яшьтән алып белем бирү мөнәсәбәтләре туктатылганга кадәр |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 3-4 | 33,88 | 42,65 | | |
| 5-6 | 81,28 | 102,39 | | |
| 7-12 | 135,49 | 170,64 | 175,78 | 234,39 |
| 24 | 169,34 | 210,66 | 219,73 | 289,36» |

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче И. Х. Хәмидуллин